**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2022 елның «01» апреленнән № 110

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 6 сентябрендәге 367 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 6 сентябрендәге 367 номерлы карары белән расланган административ регламентның 1.5 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«6) шәхси торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү («Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш).».

2. «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 6 сентябрендәге

367 номерлы карары белән расланган административ регламентның 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 11 пунктча белән тулыландырырга:

«11) бер рәттә блокировкаланган барлык йортларның хокук ияләренең, блоклы төзелештәге бер йортны реконструкцияләгән очракта, ризалыгы.».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов